ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.04.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1057**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2021/2022 елның ягып җылыту чоры тәмамлану һәм «2021/2022 елның ягып җылыту сезоны башлану турында» 2021 елның 15 сентябрендәге Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2237 номерлы карарын үз көчен югалтуын тану хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы нормативтан югары (+ 8°С) булу белән бәйле, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җылылык энергиясен төрле билгеләнештәге биналарны җылытуга җибәрүче предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә 2022 елның 4 маенда Зеленодольск муниципаль районы территориясендә ягып җылыту чорын тәмамларга тәкъдим итәргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2021/2022 елның җылытып ягу сезоны башлану турында» 2021 елның 15 сентябрендәге 2237 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Тышкы һава температурасы кискен төшкән очракта, җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче предприятиеләргә һәм җылылык белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләренә бүлмәләр һәм торак биналар эчендә җылылык җибәрүне күздә тотарга.
4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында( http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ), «Зеленый Дол» и «Яшен Үзән» басмаларында урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев